ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ ӘДӘБИЯТЫН (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН) ЯҢАРТЫЛГАН ФЕДЕРАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

КАЗАН
2023

ББК 74.202

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән
килешенеп, «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә
профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф
учреждениесенең **гыйльми советы карары нигезендә басыла**

**Гомуми редакция:**
Ногманова Л.Н., Татарстан Республикасы
Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогия фәннәре докторы;
Шәмсетдинова Л.П., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының фәнни
һәи инновацион эшчәнлек буенча проректоры,
химия фәннәре кандидаты

**Рецензентлар: Зиннатуллин Р.К.,** Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты; **Җамалетдинова З.И.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

**Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты; **Хадиева Г.В.**, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы; **Гыйләҗева Л.Г.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты; **Фәттахова Р.Ф.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты, **Шакирова Г.М.,** татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты, **Вагапова Ә.Р.**, татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ) ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ ӘДӘБИЯТЫН (ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН) ЯҢАРТЫЛГАН ФЕДЕРАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ УКЫТУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ / төз.:
Р.Р.Шәмсетдинова, Г.В.Һадиева. — Казан: Татарстан Республикасы
Мәгарифне үстерү институты, 2023 — 16 б.

Хезмәт белем бирү оешмаларында эшләүче туган (татар) тел һәм әдәбият укытучыларына, мәктәп җитәкчеләренә, милли мәгариф хезмәткәрләренә тәкъдим ителә. Туган (татар) тел һәм әдәбияты буенча яңатырган стандарт һәм Федераль белем бирү программасын исәпкә алып эш программмаларына үзгәрешләр кертү, укыту процессын оештыру буенча буенча методик тәкъдимнәр бирелә.

© ТРМҮИ, 2023

2023/2024 уку елында мәгариф системасында яңалык Федераль белем бирү программалары (ФОП) белән бәйле. 2022 нче елның 16 ноябреннән 993 нче номерлы приказ нигезендә Россия Федерациясендә Федераль белем бирү программалары (ФОП) гамәлгә кертелде.

Төп белем бирүнең Федераль белем бирү программалары 3 өлештән торырга тиеш: максатчан, эчтәлек һәм оештыру.

Федераль белем бирү программалары максатчан өлеше түбәндәгеләрдән тора:

- ✓ аңлатма язуы;
- ✓ укучылар үзләштерергә тиешле планлаштырылган нәтиҗәләр;
- ✓ планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешүне бәяләү системасы.

Федераль белем бирү программаларының эчтәлек өлеше шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәлернә ирешүгә юнәлтелгән түбәндәге программаларны үз эченә ала:

- ✓ уку предметларының Федераль белем бирү программалары;
- ✓ укучыларда универсаль уку гамәлләре формалаштыру программасы;
- ✓ тәрбия буенча федераль эш программасы.

Универсаль уку гамәлләре формалаштыру программасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- ✓ универсаль уку гамәлләренең уку предметы эчтәлеге белән бәйләнешнең тасвирламасы;
- ✓ укучыларның регулятив, танып белү һәм коммуникатив гамәлләрнең характеристикасы.

2023 елның 1 сентябрененә Белем бирү программаларын (ООП) Федераль белем бирү программасы (ФОП) таләпләренә туры китереп яңартырга кирәк. Белем бирү программаларын (ООП) тулысынча Федераль белем бирү программасына (ФОП) күчерү мөмкин түгел, чөнки стандарт таләп иткән программа компонентлары әлегә юк. Әлбәттә, Федераль белем бирү программасыннан (ФОП) күчереп алырга мөмкин, ләкин барлык очракларда да түгел. Әгәр сезнең мәктәп тулысы белән яңартылган ФДББСына күчмәгән булса, сезгә барлык программаларны да карап чыгарга кирәк булачак – ФДББС 2021 буенча эшләнгәнен дә һәм иске ФДББС буенча эшләгән белем бирү программаларын (ООП) да. Федераль белем бирү программасы (ФОП) һәм ФДББС буенча максатчан бүлекнең барлык компонентларын карап чыгарга һәм төзәтергә кирәк: аңлатма язуы, планлаштырылган нәтиҗәләр, бәяләү системасы.

ФОПтагы УУГ формалаштыру программасының эчтәлеге икенче һәм өченче буын стандартлардан аерыла. Шуңа күрә программаны яңартканда белем бирү стандартына таянырга кирәк. Программаның эчтәлеге, шулай ук, иске һәм яңа стандартларда аерыла. ФОП буенча УУГ формалаштыру программасына ФДББС таләбе һәм аның эчтәлеге түбәндәге таблицада чагылыш тапкан.

*Төп гомуми белем бирү баскычында УУГ формалаштыру яки үсеше программасының структурасы*

| **ФОП** | **ФДББС 2021** |
|---|---|
| Эчтәлегендә:<br>– УУГнең уку предметы эчтәлеге белән бәйләнешен күрсәткән тасвирламасы; | Эчтәлегендә:<br>– УУГнең уку предметы эчтәлеге белән бәйләнешен күрсәткән тасвирламасы; |

| | |
|---|---|
| – укучыларда танып белү, коммуникатив, регулятив УУГ характеристикасы | – дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында уку-тикшеренү эшчәнлегенең төп формаларын һәм юнәлешләрен тормышка ашыру үзенчәлекләренең тасвирламасы |

«Туган (татар) теле» һәм «Әдәбият» предметы буенча мәктәптә дәрес кысаларында укучыларның тикшеренү эшчәнлеген оештыруның түбәндәге формалары тормышка ашырыла ала:

– дәрес-тикшеренү;

– тикшеренү максатыннан интерактив әңгәмә кулланып үткәрелгән дәрес;

– тикшеренү эшчәнлеге элементларын үзләштерергә мөмкинлек бирә торган дәрес-эксперимент (экспериментны планлаштыру һәм үткәрү, аның нәтиҗәләрен анализлау һәм эшкәртү);

– дәрес-консультация;

– өй эше кысаларында мини-тикшеренү.

Укучыларның уку белән бәйле тикшеренү нәтиҗәләрен тәкъдим итү формалары:

– доклад, реферат;

– предмет буенча тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен чагылдырган мәкаләләр, күзәтүләр, отчетлар.

Дәрестән тыш эшчәнлек буенча уку тикшеренүләре түбәндәге юнәлешләрдә тормышка ашырыла:

– социаль-гуманитар;

– филологик;

– табигый-фәнни;

– мәгълүмати-технологик;

– дисциплинара.

Дәрестән тыш эшчәнлектә укучыларның уку тикшеренү эшчәнлеген оештыруның төп формалары:

– конференция, семинар, дискуссия, диспут; брифинг, интервью, телемост;

– тикшеренү практикасы, белем алу экспедициясе, походлар, сәяхәтләр, экскурсияләр;

– укучыларның фәнни-тикшеренү җәмгыятьләре.

Укучыларның уку тикшеренү эшчәнлеге нәтиҗәләрен тәкъдим итүдә түбәндәге формаларны сайларга мөмкин:

– язма тикшеренү эше (эссе, доклад, реферат);

– тикшеренү экспедицияләре, архивларны эшкәртү, төрле предмет өлкәләрен өйрәнү кысаларында мәкалә, күзәтү, отчет һәм нәтиҗәләр ясау.

**Яңартылган ФДББС кысаларында эш программалары белән бәйле үзенчәлекләр**

Белем бирү оешмасы ФДДБС 2021 белән эшләгәндә, эш программаларын төзегәндә билгеле бер авырлыклар килеп чыгарга мөмкин. Экспертлар эш программаларын анализлап, 5 очракны аерып чыгарганнар һәм төгәлсезлекләрне бетерү юлларын күрсәткәннәр.

**1. Эш программасының структурасы ФДББСка туры килми.** *Мәсәлән: кайбер педагоглар ФДББС 2021гә күчкән 5 сыйныф укучыларын һәм икенче буын стандартлар буенча укуны дәвам иткән 6 – 9 нчы сыйныф укучыларына да бертөрле программалар эшлиләр.*

Бу уку елында мәктәпләр беренче мәртәбә икенче һәм өченче буын ФДББС буенча педагоглар эшләгән эш программаларын гамәлгә ашыра. Укытучыларда туган төп авырлык – яңа һәм иске белем бирү стандарт таләбе буенча документның структурасында. Мәсәлән, мәктәп бары тик 1нче һәм 5 нче сыйныфларда ФДББС 2021гә күчкәндә, педагоглар дәресләрне бу сыйныфларда гына үткәрми. Мондый очракта укытучылар эш программаларын вакытны экономияләү максатыннан бер үк шаблон буенча эшләргә мөмкин. Ләкин бу документларда хаталарга китерәчәк. Укытучыларда әлеге проблема тумасын өчен түбәндәге таблицаны тәкъдим итәргә мөмкин.

**Эш программалары структурасына ФДББС таләпләре**

| **Икенче буын ФДББС** | | **Өченче буын ФДББС** |
|---|---|---|
| Уку предметларының, курсларның эш программалары | Дәрестән тыш эшчәнлек курсының эш программасы | Уку предметы, курс, модульләренең (шул исәптән дәрестән тыш эшчәнлекнең дә) эш программалары |

| | | |
|---|---|---|
| 1. Уку предметы, курсны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре<br>2. Уку предметы, курсның эчтәлеге<br>3. Тәрбия эш программасын чагылдырган тематик планлаштыру (һәр темага ) | 1. Дәрестән тыш курсны үзләштерү нәтиҗәләре.<br>2. Оештыру формалары һәм эшчәнлек төрләре белән дәрестән тыш эшчәнлек курсының эчтәлеге.<br>3. Тәрбия буенча эш программасын чагылдырган тематик планлаштыру | 1. Уку предметы, курсы яки модульнең эчтәлеге.<br>2. Уку предметы, курсы яки модульнең планлаштырылган нәтиҗәләре.<br>3. Һәр тема буенча электрон белем бирү ресурсы (ЭОР) яки цифрлы белем бирү ресурсы (ЦОР) куллану мөмкинлеген һәм академик сәгатьләр санын күрсәткән тематик планлаштыру |

Әгәр дә эш программасы ФДББС таләбенә туры килми икән, тикшерүчеләр белем бирү стандартында беркетелгән нормаларны мәктәп үтәми дигән нәтиҗә ясаячак. Әлеге очракта санкция – кыска срокларда бу төгәлсезлекне бетерү. Әгәр дә әлеге хата ачыкланган икән, аны шунда ук төзәтергә кирәк.

**2. Һәр тема буенча электрон белем бирү ресурсы (ЭОР) яки цифрлы белем бирү ресурсы (ЦОР) куллану мөмкинлеген күрсәтмәү.** *Мәсәлән, укытучыларның бер өлеше һәр тема буенча электрон ресурсларны күрсәтмәгән. Ә бер укытучы программада федераль исемлеккә кермәгән электрон ресурсларны санап чыккан.*

Тематик планлаштыруда һәр тема буенча электрон яки цифрлы белем бирү ресурсы күрсәтү таләбе бары тик ФДББС 2021 буенча педагоглар төзелгән эш программаларына гына карый. Моннан кала документларда

санап кителә торган электрон һәм цифрлы ресурслар федераль исемлеккә кергән булырга тиеш (02.08.2022 елның №658 приказы). Әгәр дә эш программасында электрон һәм цифрлы ресурслар күрсәтелмәгән булса, федераль исемлекне өйрәнергә тәкъдим итәргә була. Укытучыга бу эштә методик берләшмә җитәкчеләре дә ярдәм итә ала.

**3. Һәр тема буенча эчтәлекнең тәрвияви потенциалы күрсәтелмәгән.**

*Мәсәлән, эш программасында педагогларның бер өлеше генә һәм тема буенча тәрвияви компонентны күрсәткән. Гәрчә барлык педагоглар бу компонентны аңлатма язуында күрсәткән булсалар да.*

Икенче һәм өченче буын стандартлары эш программаларында тәрвияви компонент буенча таләпләрне үз эченә ала. Әгәр дә педагоглар бу эшне башкармаган булса, тикшерүчеләр мәктәп белем бирү стандартларын тормышка ашырмый дигән кисәтү ясаячаклар.

ФДББС 2021 укытучыларны предмет, курс, модуль буенча эш программаларында тәрбия буенча эш программасын гамәлгә ашыруны таләп итә. (ФГОС-2021 НОО п.31.1., ФГОС-2021 ООО п.32.1.). Ләкин стандарт эш программасының кайсы өлешендә эшләргә кирәклекне искәртми. Мәктәп бу сорауны үзе хәл итә. Икенче буын ФДББС өчен Мәгариф министрлыгы үзгәрешләрне гамәлгә кертте. Алар шулай ук эш программасында тәрвияви компонентын чагылдыруны ныгытып куя, нәкъ менә тематик планлаштыруда. (11.12.2020 №712 приказ белән расланган, пп. 1.3., 2.3. үзгәрешләр)

Мәктәп дәрәҗәсендә эш программаларында тәрбия буенча эш программмасын чагылдыра торган бердәм якын килүне сайларга тәкъдим итәбез. Мәсәлән, локаль акт белән тематик планлаштыруда тәрвияви компонентны беркетүне билгеләп куярга кирәк. Шулай ук, педагоглар эш программасын хатасыз һәм бердәм формада эшләсен өчен өстәмә рәвештә шаблоннар һәм методик күрсәтмәләрне бирергә мөмкин.

*Мисал.*

**Татар теле буенча тематик планлаштыру шаблоны, 5 нче сыйныф**

| **Сәгать саны** | **Тема** | **Тәрбия максатлары** | **Тәрбия программасы** | **ЭОР, ЦОР** |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

**4. Эш программасының эчтәлеге ФДББСына туры килми.**

*Мәсәлән, укытучы эш программасының эчтәлегенә конкрет бер теманы кертмәгән. Икенче буын ФДББС буенча темалар буенча да үзгәрешләр булырга мөмкин.*

1 нче һәм 5 нче сыйныфлар өчен педагоглар төзегән эш программалары ФДББС 2021 туры килергә тиеш. Укытучылар белем бирү стандартларын бутамаган икәнен һәм икенче буын ФДББС эчтәлеген документларга кертмәгәнлеген ачыкларга кирәк. Бу исә җитди хата – педагог уку елы дәвамында башка белем бирү стандартын гамәлгә ашырган булып чыга.

Икенче буын ФДББСына уку предметы эчтәлегенә дидактик берәмлекләр керми. Эш программасының эчтәлеген эшләү өчен укытучыга белем бирү стандартында предмет нәтиҗәләренә һәм белем бирү дәрәҗәсеннән чыгып Үрнәк гомуми белем бирү программасының эчтәлек өлешенә ориентлашырга кирәк. Ә инде киләсе уку елыннан педагоглар Үрнәк гомуми белем бирү программасы урынына Федераль белем бирү программасына (ФОП) нигезләнеп эшләргә тиеш. Өченче буын стандартларда предмет буенча планлаштырылган нәтиҗәләр фигыль формасында конкрет дидактик берәмлек буларак беркетеп куелган.

**5. Планлаштырылган нәтиҗәләр ФДББСка туры килми.**

*Мәсәлән, 5 нче сыйныф дәреслегендә педагоглар планлаштырылган нәтиҗәләрне белем бирү дәрәҗәсеннән чыгып мәктәпнең белем бирү*

*программасындагы максатчан бүлектәге нәтиҗәләр белән туры килми. Ә беренче сыйныф укытучысы планлаштырган нәтиҗәләрне ФДББС таләп иткәнчә конкретлаштырмаган.*

Өченче буын стандартны эшләүчеләр предмет нәтиҗәләренең барлык төрләрен дә детальләштерделәр һәм киңәйттеләр. Педагогларга моны 1-нче һәм 5-нче сыйныф өчен программаларда чагылдырырга тиешләр. Ә менә 2-4 нче һәм 6-9 нчы сыйныфлар өчен документларны бу елда икече буын стандартлар буенча калдырырга мөмкин.

Яңа ФДББС буенча мәктәп укучының шәхес буларак үсешен 8 юнәлеш буенча алып бара, аларның һәрберсе документта детальләштереп бирелгән. Метапредмет нәтиҗәләре икенче һәм өченче буын белем бирү стандартларында 3 юнәлештә бирелә: танып белү, коммуникатив һәм регулятив. Шулай да, яңартылган стандартларда алар конкретлаштырып тәкъдим ителгән.

Уку предметы буенча эш программаларында предмет нәтиҗәләренең формулировкалары ФДББС таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерегез. Шул ук вакытта алар мәктәпнең белем бирү дәрәҗәсеннән чыгып белем бирү программасының (ООП) максатчан бүлегендә беркетелгән нәтиҗәләргә дә туры килергә тиеш.

Әгәр дә эш программаларын тикшерү нәтиҗәләре буенча планлаштырган нәтиҗәләр иске яки яңа ФДББС туры килмәвен ачыкласагыз, бу проблеманы кичекмәстән хәл итегез.

**Яңартылган ФДББС буенча «Туган (татар) тел» һәм «Әдәбият» предметын укыту**

Мәгариф системасында үзгәрешләр мәктәптә укытыла торган предметларны укыту эчтәлегенә һәм формаларына да тәэсир итә. Яңартылган стандартлар предметларның укытуның максатларын да билгеләде. Димәк, һәр укытучыга укыту процессында бу максатларны күз алдында тотып эшләргә кирәк.

Сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен камилләштерү (сөйләшү, тыңлау, уку, язу) – мәктәптә туган (татар) тел өйрәнүнең төп максаты. Ул мәктәп циклының барлык предметларын өйрәнү кысаларында бара, әмма бары тик туган (татар) тел дәресләрендә генә максатчан характер йөртә. Шул максаттан чыгып, туган (татар) тел буенча Үрнәк эш программасында «Тел һәм сөйләм», «Текст», «Сөйләм культурасы» дигән махсус бүлекләр каралган. Шул ук вакытта сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрен камилләштерү татар телен өйрәнүнең барлык темаларын үткәндә дә өйрәнелергә мөмкин һәм ул яңгыраган сөйләмне аңлы рәвештә кабул итү һәм аңлау сәләте (тыңлау күнекмәсе) һәм басма сүз (укый белү күнекмәсе); аралашу шартларын исәпкә алып, үз фикереңне дөрес, төгәл, сәнгатьле итеп, логиканы саклап, телдән һәм язма формада җиткерә белү (сөйләшә һәм яза белү күнекмәсе).

Татар теле һәм әдәбияты фәннәрен төп гомуми белем бирү мәктәбендә укытканда функциональ грамоталылык формалаштыру – шулай ук яңартылган ФДББСның таләпләренең берсе. Татар теле һәм әдәбиятын укытуның максатлары да укучыларда функциональ грамоталылык формалаштыру белән бәйле булырга тиеш.

Әлбәттә, татар теле һәм әдәбияты укытучысы укучыларда беренче чиратта уку грамоталылыгын формалаштыра, ул исә укуга өйрәтүгә генә кайтып калмый. Уку грамоталылыгы мәгънәви уку, укылганнан мәгънә эзләү, текстның язу максатын билгеләүне дә үз эченә ала. Уку грамоталылыгы

формалаштыру максатчан рәвештә укучыларны тормышка якынайтылган төрле ситуацияләрдә төрле жанрдагы мәгълүмат белән эшләргә өйрәтү: сүзлекләрдән, энциклопедияләрдән, белешмәлекләрдән, интернет-сайтлардан мәгълүматны эзләү, аны интерпретацияләү һәм уку өчен яки шәхси максатларда куллану; текстны уку, мәгълүмати-мәгънәви эшкәртү тактикасы һәм стратегияләре; авторның коммуникатив максатын аңлауны үз эченә алган төрле текстларны аңлау ысуллары өйрәнү.

Шул уңайдан татар теле дәресләрендә лингвистик анализга сайлап алынган текстларның һәм әдәбият дәресләрендә өйрәнелә торган әдәби әсәрләрнең мәгънәви ягына игътибарны көчәйтергә кирәк. Текстка өстәмә рәвештә түбәндәге сорауларны бирергә мөмкин:

*– Бу текст / әсәр нәрсә турында?*

*– Автор нәрсә әйтергә теләгән? Ул укучыга нинди фикер җиткерергә тели?*

*– Текстның композициясе нинди, аның үзенчәлекләре нәрсәдә?*

*– Һәр абзацның төп идеяләре/фикерләре нинди?*

*– Текстның мантыйгы ничек чагылыш таба?*

*– Ни өчен текстка / әсәргә нәкъ менә шушы иллюстрация сайлап алынган? Ул нинди мәгънәне чагылдыра?*

*– Тексттагы мәгълүматны схема, таблица, инфографика, рәсем һ.б. рәвешендә күрсәтергә мөмкинме?*

Шулай ук, татар теле һәм әдәбияты укытучысы укучыларның креатив фикерләвен үстерү өлкәсенә дә

**Яңартылган ФДББС таләпләре буенча дәрес**

ФДББС 2021 үзгәрешләр дәреснең эчтәлегендә, дәрестә кулланыла торган алымнар һәм эш формаларында һәм структурасында да чагылыш таба. Предметларны укытканда стандартта чагылыш тапкан предмет, метапредмет һәм шәхескә кагылышлы нәтиҗәләрдәге үзгәрешләрне дә исәпкә алырга кирәк.

ФДББС 2021 буенча дәреснең структурасы түбәндәге таблицада чагылыш тапкан.

*ФДББС буенча дәрес структурасы*

| **Дәрес этабы** | **Кыска эчтәлек, укучыларның эш-гамәлләре** | **Укытучының эш-гамәлләре** |
|---|---|---|
| Уку эшчәнлегенә мотивлаштыру | Уңай дәрес атмосферасын булдыру | Укучыларны уңышлы эшчәнлеккә көйләү |
| Белемнәрне актуальләштерү | Үткәннәрне кабатлау, биремнәрне эшләү. Үзара тикшерү һәм үзара бәйләү. Аннан укучылар булган күнекмәләр белән эшли алмаслык бирем алалар. | Консультация бирә |
| Максат кую, проблеманы кую | Уртак эшчәнлек барышында авырлык туу сәбәпләре ачыклана, проблема билгеләнә. Укучылар мөстәкыйль рәвештә | Дәреснең тема, максат, бурычларын аңлап, укучыларны белү һәм белмәү чикләрен билгеләүгә китерә. |

| | | |
|---|---|---|
| | тема һәм максатны билгели. | |
| Проблеманы хәл итү юлларын эзләү | Куелган максатка ирешү юлларын планлаштыру. Практик мәсьәләләрне чишүгә юнәлтелгән индивидуаль яки төркемдә эш | Консультация бирә |
| Проблеманы чишү | Чишеп булмаслык биремне эшләп карау | Консультация бирә |
| Коррекция | Карарны тикшерәләр, биремне үти алдыларммы, кыенлыклар формалаштыралар. | Ярдәм итә, киңәш итә, консультация бирә. |
| Алынган белемнәрдән файдаланып, мөстәкыйль эш | Яңа тема буенча күнегүләр башкару, эталон буенча үз-үзеңне тикшерү | Консультация бирә |
| Белемнәрне системалаштыру | Дәрестә өйрәнелгән тема белән элек өйрәнелгән материал, тормыш арасында бәйләнешне ачыклау | Консультация бирә, юнәлеш бирә |
| Өй эшен аңлату | Укучыларның үз кызыксынуларыннан чыгып сайлау мөмкинлеге булырга | Аңлата, сайлап алуга биремнәр тәкъдим итә |

| | | |
|---|---|---|
| | тиеш. Биремнәр төрле катлаулылыкта булуы кирәк. | |
| Бәяләү | Укучылар эшне мөстәкыйль рәвештә бәялиләр (үз-үзен бәяләү, сыйныфташларының эш нәтиҗәләрен үзара бәяләү) | Консультацияли, бәяләүләрне нигезли |
| Уку эшчәнлеге рефлексиясе | Укучылар дәрес темасын, аның этапларын атыйлар, һәр этапта эшчәнлек төрләрен санап чыгалар, предмет эчтәлеген билгелиләр. Дәрестә үз эшчәнлекләре турында фикерләрен әйтәләр. | Укучыларга дәрес өчен рәхмәт әйтә |